**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОСТАВЫНА КЕРҮЧЕ КАЛМАШ АВЫЛЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА**

**КАРАР**

24 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- Калмаш авылында урам утларын ремонтлау;
- Калмаш авылы юлларын ремонтлау.
- Калмаш авылы су үткәргеч челтәрен алыштыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **1199** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **599** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **591** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **8** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби

хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне :

- Калмаш авылында урам утларын ремонтлау;
- Калмаш авылы юлларын ремонтлау.
- Калмаш авылы су үткәргеч челтәрен алыштыру.

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен http://tukay.tatarstan.ru Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы

Ф.В.Шавалиев